10 МАРТА НАШЕМУ ЗЕМЛЯКУ ПИСАТЕЛЮ, ПРОЗАИКУ
И ПОЭТУ –ЛИРИКУ ИСПОЛНЯЕТСЯ 97 ЛЕТ. НА СЕГОД –
НЯШНИЙ ДЕНЬ ЕГО КНИГИ НЕ ПЕРЕИЗДАЮТСЯ, ПОЭТОМУ
ИХ НАЙТИ И ПРОЧИТАТЬ ОЧЕНЬ СЛОЖНО. Я ХОЧУ , ЧТОБ
ТВОРЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ НАШЕГО ПИСАТЕЛЯ ЗЕМЛЯКА
БЫЛ ДОСТУПНЫМ КАЖДОМУ. Я ПРЕДЛАГАЮ ВАМ ДЛЯ
ЧТЕНИЯ РАССКАЗ ЯРУЛЛЫ ВАЛЕЕВА
«СУЛАРДА ДУЛКЫНЛАНЫП…»



## ЯРУЛЛА ВӘЛИЕВ

*Ярулла Вәлиев 1921 елның 10 мартында Башкортстанның Нуриман районындагы Бикмырза авылында туа. 1938—1941 елларда аның байтак шигырьләре өлкә газеталарында, әдәби альманахларда басыла. Күп санда юмористик һәм сатирик хикәяләр язды. Аларның бер өлеше 1963 елда чыккан «Үз кеше» китабына кертелгән. 1963 елда «Хәерле иртә, Исмәгыйль!», 1965 елда «Көчле кошчык син, сыерчык!», 1967—1968 елларда «Сүнми дә, сүрелми дә» повестьларын язды. Шулай ук ул «Бөркетләр оя ташламый» исемле романын тәмамлады.*

*Ярулла Вәлиев 1942 елдан КПСС члены.*

# СУЛАРДА ДУЛКЫНЛАНЫП...

Кышкы бөркәнчеген яңа гына салып ташлаган басу, йокысыннан уянган баһадир сыман, кояшның җылы нурларына куанып иркен сулап ята. Аның күкрәгеннән сы-



зылып ак пар күтәрелә. Тын. Зәңгәр күктә сабан тургае гына үзенең шат җырын суза. Әйтерсең, игенченең буразнага беренче аяк басуын котлый.

Күңелле кошчык! Гүя ул кешенең дә гел күңелле булуын тели. Көндезен өзлексез көйли дә көйли ул. Көн буе аның чыр-чыр чыңлавы колактан китми. Трактор гүләгәндә генә тынып тора кебек. Ә ялга туктадыңмы, тагын да концерт бирергә тотына.

Басуга беренче «кул салып», хезмәт язын башлап җибәргән Таһир, шушы хозур тамашага соклана-соклана, Агыйдел буена китте. Сабан тургае да аннан калмады. Әйтерсең, төнге ялга туктаганчы, сменасын тапшырган дустын үзенең моңы белән озатырга чамалый. Таһир аны ихлас тыңлый. Аңа кушылып үзе дә җырлап җибәрә.

Очтың тургай, очтың тургай,
Күкләрдә булдың бугай.
Күкләрдә син белмәдеңме,
Минем иркәм ни уйлый?

Агыйдел Бикназар авылын нәкъ урталай бүлеп ага. Икенче көн инде анда боз китә. Икенче көн инде Агыйдел, кышкы әсирлектән котылып, ireккә чыгуына куанган шикелле, ярларына сыеша алмыйча, күпереп-бүртенеп ургыла, ыжгыра, Таһирны үчекләгән шикелле шаркылдап көлә.

Таһир өмет белән аръякка карый. Анда, уң якта — Рәхилә. Дүрт көн була инде Таһирның аны күрмәвенә. Ул, боз кузгалганчы дип, тракторын бу якка алып чыкты. Шуннан Рәхиләне күрә алмады. Чәчү алды көннәренең ыгы-зыгысы билгеле бит инде.

Таһир, ике күзен тутырып, уң яктагы кыяны күзәтә. Сокландыгыч кыя ул. Читтән караганда биек күперне хәтерләтә. Яртылаш диярлек Агыйдел өстенә чыгып тора. Түбәсе, ындыр табагы сыман, тап-такыр аның. Язынҗәен яшь-җилкенчәк шушында уенга җыела. Бүген дә анда җыр яңгырар, биерләр, уйнар-көләрләр.

Рәхиләне дә былтыр беренче мәртәбә шушында очратты Таһир. Шулай, август кичендә бер ят кыз бирегә төште. Күбәләктәй җиңел, орчыктай җитез иде ул. Бирелеп, җилкенеп биеде. Бер мәлне, кемне чакырырга белмичә, тукталып калды да тирә-ягына каранып алды. Якынрак торгангадырмы, очып килеп, Таһирга басты.

— Кем бу? — дип сорады Таһир иптәшләреннән.

— Яңа фельдшер,— диделәр.

Шул көннән тынычлыгын югалтты Таһир. Яңа фельдшер көндез исендә йөрде, төнен төшкә керде. Бик озак теше «сызлап» йөдәтте. Рәхилә аны игътибар белән карый торган булды. Әмма авыру тешне һич тә таба алмады. Аптырагач:

— Сезнең тешләрегез имәндәй нык бит,— дип баш чайкый иде. «Теш авыруының» йөрәктә икәнен сизми иде шул. Вакыт үтә торды. Алар бер-берсеннән ияләшә төште. Тик хисләрен һәрберсе үзендә саклый иде.

Язгы гөрләвекләр шаулаган, йөрәкләргә дә яз шаукымы тигән бер көнне Таһирның күзенә «тигәнәк керде». Эштән соң, аулаграк чакка туры китереп, Таһир Рәхиләнең фатирына килде.

— Үләм, күземне ача да алмыйм! — диде ул. Рәхилә «тигәнәк»не озак эзләде. Шуннан Таһирга гаҗәпләнгән сымаграк карап алды.

— Чүп чыкты бугай. Җиңел булып калды,— диде Таһир, кызара биреп. Алар бер-берсенә озак карашып тордылар. «Мин сине сөям», дип әйтергә берничә кат омтылып карады Таһир, ләкин авызыннан сүз чыкмады. Аны дәртләндергәндәй, Рәхилә көлемсерәп куйды.

— Рәхилә...

— Тагын кай җирең авырта, Таһир? — диде Рәхилә, һаман елмаеп.

— Яратам мин...

— Ә ул? Ул яратамы соң?

— Белмим. Ул... Үзе... Үзең...

Шуннан бөтен кыюлыгын җыеп, ярып салды:

— Мин бит сине яратам, Рәхилә!

Рәхилә бер сүз дә әйтмәде, өстәлдә яткан хатка күз салып алгандай булды. Таһир Рәхиләгә кемнәндер хат килеп торуын белә иде. Шикләнсә дә сиздермәскә тырышты. Сорарга да кыймады. Әдәпсезлек булыр, дип курыкты. Нинди хат икән ул?

Таһир күңелендәге шикләрен куарга тырышты.

Менә хәзер Агыйдел, ташкан һәм шашкан Агыйдел аера аларны. Нишли икән анда Рәхилә? Кыяга чыгармы?

Таһирның йөзе кинәт яктырып китте. Кыяда Рәхилә басып тора. Баш очына күтәреп, күк косынкасын болгый. Таһир фуражкасын чөйде. Аңа рәхәт иде. Гашыйк күңеленә күп кирәкмени! Рәхиләнең зәңгәр күзләрен күргән, сары чәчләреннән сыйпап иркәләгән, йомшак кулларын үз учларында тоткан төсле тойды ул үзен.



Тукта, ни булды? Нигә сөреме коелды Таһирның? Ул Рәхилә янындагы ят егетне күрде. Йөрәгеп нидер чеметеп алды.

Ярдәм эзләгәндәй, күккә карады. Анда сабан тургае талпына. Кинәт, кайдандыр, тилгән килеп чыкты да тургай өстенә ташланды. Тургай, ук сыман, җиргә атылды. Ышыкланыр урын эзләде. Таба алмагач, күп уйлап тормый, Таһирның артына килеп посты.

Гаҗәпләнүенең чиге юк иде Таһирның. Бер генә минутка ул үзенең кичерешләрен онытып торды. Тик бер генә минутка... Шунда ук хәтерләде. Әрнүе тагын да көчәя төште. Теге егет тә тилгән түгелме? Таһирның бу якта бүленеп калуыннан файдаланып, Рәхиләне тибәргә килмәгәнме? Бәлки, теге хатлар да аннан булгандыр?

Шулай уйлый Таһир. Күңеленә берсеннән-берсе яман шик килә. Тик аларны ничек чишәргә? Ул моңа көчсез иде.

Авылның ике ягында да уенга чыккан яшьләрнең күңелле җырлары, шат көлешүләре яңгырап торды. Таһир боларны ишетмәде. Бүленеп калган болан баласыдай, уң як ярдан күзен алмый утырды да утырды. Икенче әтәч тә кычкырды инде. Яшьләр таралышты. Кызын озатып йөргәндерме, соңлаган гармунчы тына тальянына кушылып, җырлап үтте.

Агыйделкәй ага ярсып,
Ашкынып-алкынланып.
Яннарына барыр идем
Суларда дулкынланып...

Таһирның ансыз да ярсу йөрәген ярып үтте, ук булып кадалды бу җыр. «Суларда дулкынланып...» Утырган ташыннан сикереп торды. Җыр аңа юл күрсәтә түгелме? Шашкан, ташкан Агыйдел аның мәхәббәтеннән көчлемени? Юк, юк!

Таһир, тиз генә күзенә чалынган беренче көймәне суга тартып төшерде дә, аның өстенә сикерде. Ташкын өереп алды көймәне, йомычка шикелле бәргәли, суккалый башлады. Таһир, юлбарыс җитезлеге белән, ишкәкләргә ябышты да, җан ачуы белән ишә башлады.

Таһир көчле, ташкын аннан да көчлерәк. Үч иткәндәй, төнгә каршы җил күтәрелгән. Дулкыннар көймәне капларга, кыю егетне упкын кочагына ташларга тели. Көймәнең борыны бер күтәрелеп, бер төшеп китә. Таһир тешен кысып ишкәккә асылына, көймә инде чумды

дигәндә, аны икенче дулкын өстенә күтәрә. Көчле агым көймәне дулкын уңаена тарта. Таһир аның саен көчлерәк ишә.

Көймәнең читенә хәтле су җитә. Дулкын уңайга китереп бәрдеме — ташкын кочагына чумуыңны көт тә тор. Таһир, кулыннан ишкәкләрен ычкындырмый гына, итекләрен салып ыргытты. Артына әйләнеп карады. Яр якын. Кыяга да ерак калмаган. Түбәнрәк китсәң, чыгарлык түгел...

Таһир сул ишкәген аркылы куеп, уңы белән ишәргә тотынды. Чамасыз көчкә чыдый алмыйча, ишкәк сынып чыкты. Көймә капланып төште. Таһирны ташкын әләктереп алды. Салкын су тәнен көйдерде, аяк-кулларын корыштырды. «Болай булса, Рәхиләне күрә дә алмассың,— дип йөзәргә тотынды ул. Өскә калкып чыкты. Янә дулкын астында калды, тагын күтәрелде. Идел үз кочагына тартып алырга күпме генә тырышмасын, Таһир ярга омтылды.

...Кемнеңдер маңгаеннан, битләреннән иркәләвен сизеп Таһир аңына килде. Күзләрен ачты. Яшькә тыгылган Рәхиләне, ә аның янында егет кисәген күрде дә, тагын да күзләрен йомды.

— Дуамалым минем, җан кисәгем!

Бу сүзләрне Рәхилә әйтте.

— Кем ул? — дип сорады Таһир, күтәрелеп карамыйча.

— Абыем ул минем, Уфадан килгән,— диде Рәхилә.

Таһирның да күзләренә яшь тулды. Ә күктә ташкын кичеп кушылган ике яшь йөрәкне котлап, сабан тургае үзенең шат җырын сузды...

Башкорт хикәяләре. – Казан; Татарстан китап нәшрияты, 1970. – 266 - 270 битләр

Игътибарыгызга рәхмәт!

Спасибо за внимание!

SuperGif